РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 94

15 май 2018 ел

## Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә 2018елның II кварталына торак бинаның гомуми мәйданы бер квадрат метрына уртача базар бәясен раслау турында

Торак шартларын яхшырту буенча исәпкә куелган категория гражданнарга социаль түләүләр күләмен билгеләү, һәм аларга торак мәйданы алуга әлеге социаль түләүләр федераль бюджет чараларыннан бүлеп бирелгән очракта, шулай ук торак шартларын яхшырту буенча исәпкә куелган гражданнар өчен файдаланылучы башка хисапларны билгеләү, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 11апрелендә гамәлгә кергән 224нче номерлы “ 2018елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясендә торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясенә һәм Россия Федерациясе субъектларында 2018елның II кварталына торак бинаның гомуми мәйданы бер квадрат метрына уртача базар бәясе күрсәткечләре нормативы турында”гы карарына нигезләнеп, карар бирәм:

1. Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә 2018елның 1нче кварталына торак бинаның гомуми мәйданы бер квадрат метрына уртача базар бәясен 39 621 ( утыз тугыз мең алты йөз егерме бер) сум күләмендә расларга.
2. Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты торак сәясәте бүлеге башлыгы И.Н. Бәдретдиновка йөкләргә.

Җитәкче Д.И. Баландин